Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлегенең Иске Камка авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 29 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 20 номерлы Әлки муниципаль районының «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 19 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» турындагы карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегенең Иске Камка авылында 2019 елның 29 ноябрендәге 3 номерлы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге составына керүче Иске Камка авылы торак пунктында гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

- яктырту җиһазлары буенча электромонтаж эшләре һәм урамнарны яктыртуга кулланылган энергия чыгымнары өчен түләү – 100 сум;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын реконструкцияләү һәм ремонтлау, су башнясын кулланган энергия өчен чыгымнарны түләү, суны лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү-80 сум;

-юлларны карап тоту өчен кирәкле материал сатып алуга (кышын кардан чистарту, җәен үләннәрне чабу), торак пункт эчендәге юлларны ремонтлау, МТЗ-82 тракторына хезмәт күрсәтү, тракторчыга килешү буенча түләү, тракторга ягулык–майлау материаллары сатып алу өчен-260 сум.

-чишмәләрне торгызу һәм төзекләндерү өчен кирәкле материал сатып алу, чишмәләрне төзекләндерү буенча башкарылган эшләргә өчен түләү -70 сум.

-чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу (белгеч эше өчен түләү), тирес күмү - 90 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар һәм теркәлгән, ләкин яшәмәүче гражданнардан кала, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

- яктырту җиһазлары буенча электромонтаж эшләре һәм урамнарны яктыртуга кулланылган энергия чыгымнары өчен түләү – 100 сум;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын реконструкцияләү һәм ремонтлау, су башнясын кулланган энергия өчен чыгымнарны түләү, суны лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү-80 сум;

-торак пункт эчендәге юлларны карап тоту(кышын кардан чистарту, җәен үләннәрне чабу), ремонтлау өчен кирәкле материал сатып алу, МТЗ-82 тракторына хезмәт күрсәтү, тракторчыга килешү буенча түләү, тракторга ягулык– майлау материаллары сатып алу өчен- 260 сум.

-чишмәләрне торгызу һәм төзекләндерү өчен кирәкле материал сатып алу, чишмәләрне төзекләндерү буенча башкарылган эшләргә өчен түләү -70 сум.

-чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу (белгеч эше өчен түләү), тирес күмү -90 сум

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Камка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге башлыгы: Акберов Ф.А.